**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЛЫН-БАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2023 елның 21 ноябре № 142

**Болын-Балыкчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Уставна нигезләнеп Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советының«Болын-Балыкчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 2023 елның 20 гыйнварындагы 103 номерлы карары белән расланган Болын-Балыкчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4.13 пунктында икенче җөмләне алып ташларга;

2) 4.19 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3) 4.21 пунктын түбәндәге редакциядә бәянитәргә:

«4.21. Муниципаль хезмәткәрг әсыйныф чины бирү турында карар, әлеге Нигезләмәнең 4.15 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә сыйныф чины бирү турында тәкъдим кертелгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча, органга яки җирлеүзидарәнең сыйныф чинын бирергә вәкаләтле вазыйфаизатына класс чины бирү турында Карар кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсмирәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үзкөченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Болын-Балыкчы авыл**
**җирлегеБашлыгы,**
**Болын-Балыкчы авылҗирлеге**
**Советы рәисе** **Л.М.Гайнетдинов**